**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче Сатлыган авыл торак пунктында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

**2019 елның 08 ноябре** **№ 1**

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә “ Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле Казаклар Чаллысы, Сатлыган авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге формада белем алучы студентлардан , тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы юлларны кардан чистарту;
- Котлы Бөкәш авыл җирлегендәге авыл урамнарына вак таш җәю;
- Котлы Бөкәш авылының Вахитов урамында Шомбыт елгасы аша булган,Титов урамыннан Вахитов урамына чыга торган һәм Тәберде Чаллысы авылына таба Шомбыт елгасы аша салынган куперчекләрне ремонтлау;
- урам утларының светодиод лампаларына һәм авыл мәдәният йортларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;
- вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;
-Тәберде Чаллысы авылының Мәктәп урамындагы чишмә каптажын ремонтлау.

“ӘЙЕ “ “ЮК”

соравы (мәсьәләсе) буенча 2019 елның 08 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Гражданнар җыенының сайлау хокукына ия катнашучылары исемлегенә 35 кеше кертелде, тавыш бирүдә җыенда катнашучыларның 20 кешесе катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе” позициясе өчен 20 җыенда катнашучы тавыш биргән;

“Юк” позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш биргән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче Сатлыган авыл торак пунктында гражданнар җыенын **булды** дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен **дөрес** дип танырга.

2. “Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле

Казаклар Чаллысы, Сатлыган авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге формада белем алучы студентлардан, тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә һәм тупланган средстволарны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтеп түбәндәге эшләрне башкару өчен тотуга ризамы:

- кышкы юлларны кардан чистарту;
- Котлы Бөкәш авыл җирлегендәге авыл урамнарына вак таш җәю;
- Котлы Бөкәш авылының Вахитов урамында Шомбыт елгасы аша булган,Титов урамыннан Вахитов урамына чыга торган һәм Тәберде Чаллысы авылына таба Шомбыт елгасы аша салынган куперчекләрне ремонтлау;
- урам утларының светодиод лампаларына һәм авыл мәдәният йортларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;
- вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;
-Тәберде Чаллысы авылының Мәктәп урамындагы чишмә каптажын ремонтлау?”

соравы (мәсьәләсе) буенча карарны **кабул ителде** дип танырга.

3. Әлеге карарны дәүләт теркәвеннән соң өч көн эчендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы
Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче
Сатлыган авылы торак пунктында узган

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**2019 елның 08 ноябре** **№ 2**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, Татарстан Республикасының ”Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” Законының 35 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлеге составына керүче Сатлыган авылы торак пунктында узган гражданнар җыены **КАРАР БИРӘ**:

1. 2020 елда Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең Котлы Бөкәш, Тәберде Чаллысы, Мәмле Казаклар Чаллысы, Сатлыган авылы торак пунктларында тору урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешесеннән, көндезге формада белем алучы студентлардан , тумыштан инвалид булган, 1 группа инвалид, баласыз япа-ялгыз яшәүче яшьләре 80 нән узган өлкән яшьтәге кешеләрдән кала һәм аларның гомуми саны җирлектә яшәүчеләрнең 30% тан артмаган очракта, 400 сум күләмендә үзара салым акчасы кертүгә.
2. Тупланган акчаларны түбәндәгеләргә юнәлтергә:

- 2020-2021 нче елларда кышкы юлларны кардан чистарту;
- Котлы Бөкәш авыл җирлегендәге авыл урамнарына вак таш җәю;
- Котлы Бөкәш авылының Вахитов урамында Шомбыт елгасы аша булган,Титов урамыннан Вахитов урамына чыга торган һәм Тәберде Чаллысы авылына таба Шомбыт елгасы аша салынган куперчекләрне ремонтлау;
- урам утларының светодиод лампаларына һәм авыл мәдәният йортларының яктырту системасына хезмәт күрсәтү;
- вак таш тигезләү өчен трактор хезмәтләренә түләү;
- Тәберде Чаллысы авылының Мәктәп урамындагы чишмә каптажын ремонтлау.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Котлы Бөкәш авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Котлы Бөкәш авылы, Совет урамы, 32 йорт; Тәберде Чаллысы авылы, Совет урамы, 34 йорт; Мәмли Казак Чаллысы авылы, Үзәк урам, 29 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

4. Карарны Татарстан Республикасы үзидарәлек хокукый норматив актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Котлы Бөкәш авыл җирлеге башлыгы Г.Г. Нәҗипов